ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ _143_

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«23» _ноябрь,_ 2023 ел

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 121 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) суд приставы-башкаручы тарафыннан «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 229-ФЗ номерлы федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигезләр буенча башкару эшчәнлегенең тәмамлануы һәм түләттерүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, әгәр бурычның барлыкка килү датасыннан башлап биш елдан күбрәк вакыт узса, түбәндәге очракларда:»;

3 пунктта:

тугызынчы абзацта «2.1 пунктчада» сүзләрен «3 пунктчада» сүзләре белән алмаштырырга;

унберенче абзацта «3 пунктчада» сүзләрен «4 пунктчада» сүзләре белән алмаштырырга;

унөченче абзацта «4 пунктчада» сүзләрен «5 пунктчада» сүзләре белән алмаштырырга;

унбишенче абзацта «5 пунктчада» сүзләрен «6 пунктчада» сүзләре белән алмаштырырга;

унтугызынчы абзацта «6 пунктчада» сүзләрен «7 пунктчада» сүзләре белән алмаштырырга;

9 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танырга – әлеге Тәртипнең 2 һәм 2.1 пунктларында күрсәтелгән нигезләр һәм (яки) әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән документлар булганда;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танудан баш тарту – әлеге Тәртипнең 2 һәм 2.1 пунктларында күрсәтелгән нигезләр һәм (яки) әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән документлар булмаганда әлеге карар Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы мәсьәләне кабат карауга комачауламый.».

Җитәкче С.А.Крайнов